КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 6 ноябрь г.Казань № 1055

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче, 2020 ел, 24 июль, 621 нче, 2020 ел, 26 октябрь, 956 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 21 май, 353 нче; 2021 ел, 19 июль, 586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)

расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="17">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме – 26 169 608,68 мең сум*, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 17 119 908,6 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы 9 049 700,08 мең сум* тәшкил итә:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>957 036,6</td><td>668 907,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>771 639,0</td><td>631 712,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>742 042,5</td><td>683 366,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>609 879,1</td><td>721 262,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>575 168,1</td><td>755 325,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 124 229,6</td><td>766 880,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>4 587 147,4</td><td>774 413,2</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 702 633,3</td><td>847 223,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 172 547,2</td><td>792 187,2</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>2 198 901,2</td><td>792 866,8</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>839 342,3*</td><td>807 777,6*</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>839 342,3*</td><td>807 777,6*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>17 119 908,6*</td><td>9 049 700,08*</td></tr>
<tr><td colspan="3">*2024 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;</td></tr>
</table>

Программаның II бүлегендә:

унбишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

егерме сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

Программаның III бүлегендә:

икенче абзацта «27 784 579,78» саннарын «26 169 608,68» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «18 785 536,5» саннарын «17 119 908,6» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «8 998 043,28» саннарын «9 049 700,08» саннарына алмаштырырга;

Программага 1 нче кушымтаның «Һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары

белем бирелә торган мәгариф оешмаларына укырга кергән студентларның гомуми санында федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән уку өчен әлеге белем бирү оешмаларына техник белгечлекләр буенча укрыга кергән студентлар өлеше, процент» юлындагы 13 – 15 графасында «50» саннарын «-» тамгасына алмаштырырга;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы):

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы паспортында:

«Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы бурычлары» юлында:

җиденче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру йомгаклары буенча 2025 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсен 0,6 проценттан югарырак булдырмау;

халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен кимендә 61,5 процент тәэмин итү;

2025 ел ахырына эшсезлекнең уртача дәвамлылыгын 4,5 айга кадәр киметү;

теркәлгән эшсез гражданнар саныннан кимендә 12 процентының һөнәр дәрәҗәсен арттыруны тәэмин итү;

эш эзләү максаты белән халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар санының кимендә 60 процентына һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

теркәлгән эшсез гражданнарның уртача еллык саныннан кимендә 70 процентын җәмәгать һәм вакытлы эшләрдә эш белән тәэмин итүне булдыру;

республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар саныннан әлеге яшьтәге гражданнарның укудан буш вакытта эш белән тәэмин ителешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы гамәлдә булган чорда эшләмәгән инвалидлар, күпбалалы ата-аналар һәм инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен 1,2 мең махсуслаштырылган эш урыны булдыру;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күчеп урнашуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданнарга әлеге дәүләт хезмәте 100 процент күрсәтелү;

кече эшмәкәрлек өлкәсенә кимендә 5 мең эшсез гражданны җәлеп итү;

Татарстан Республикасының икътисадый актив халкы саныннан кимендә 90 процентына хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү;

730 меңнән артык гражданны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

эшкә сәләтле яшьтәге инвалидларның гомуми санында хисап чорында эшли

торган инвалидлар өлешен кимендә 30 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 55 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 65 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты һәм аннан күбрәк ай үткәннән соң эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң 6 һәм аннан күбрәк ай үткәннән соң эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан чыгарылыш укучылар өлешен кимендә 0,5 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алга таба белем алуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан чыгарылыш укучылар өлешен кимендә 12 процент тәэмин итү;

эш эзләү максаты белән мөрәҗәгать иткән пенсия алды яшендәге затлар арасында эшкә урнашу өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;»;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="8">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын финанслауның гомуми күләме 26 003 313,68 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 17 119 908,6 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 8 883 405,08 мең сум*, шулардан инвалидларны (яшь инвалидларны кертеп) эш белән тәэмин итүгә һәм эш белән тәэмин итүдә даими булышлык күрсәтеп торуны оештыруга ярдәм күрсәтү өчен – 300,2 млн.сум:<br><br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Акчаның гомуми күләме</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 611 314,39</td><td>957 036,6</td><td>654 277,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 388 721,01</td><td>771 639,0</td><td>617 082,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 410 779,48</td><td>742 042,5</td><td>668 736,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 315 776,8</td><td>609 879,1</td><td>705 897,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 315 863,1</td><td>575 168,1</td><td>740 695,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 876 479,8</td><td>1 124 229,6</td><td>752 250,2</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2020 | 5 356 930,6 | 4 587 147,4 | 769 783,2 |
| | 2021 | 2 535 226,3 | 1 702 633,3 | 832 593,0 |
| | 2022 | 2 950 104,4 | 2 172 547,2 | 777 557,2 |
| | 2023 | 2 977 138,0 | 2 198 901,2 | 778 236,8 |
| | 2024 | 1 632 489,9* | 839 342,3* | 793 147,6* |
| | 2025 | 1 632 489,9* | 839 342,3* | 793 147,6* |
| | Бар-лыгы | 26 003 313,68* | 17 119 908,6* | 8 883 405,08* |
| | *2024 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; | | | |

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының I бүлегендә:

«Инвалидларны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү, эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» бүлекчәсенең егерме дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

«Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруны тәэмин итү өчен хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» төбәк проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру» бүлекчәсе үз көчен югалткан дип танырга;

«Пенсия алды яшендәге затларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Пенсия алды яшендәге затларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру

2021 ел башына Татарстан Республикасында эшкә сәләтле яшьтәге гражданнар саны 2 162,7 мең кеше, ягъни халыкның 56 процентын, ә эшкә сәләтле яшьтән өлкәнрәк гражданнар саны – 962,1 мең кеше, ягъни халыкның 44 процентын тәшкил итте.

Пенсия белән тәэмин итүнең кайбер параметрларына төзәтмәләр кертелүгә бәйле рәвештә, халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте эшен пенсия алды яшендәге гражаннарны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүгә юнәлтү объектив зарурилык белән бәйле.

Эшсезләр составында якынча 20 процент – пенсиягә яшендәге затлар. Әлеге категорияне эшкә урнаштырганда, төп проблемалар арасында түбәндәге проблемаларны әйтеп үтәргә мөмкин: сәламәтлек торышы, квалификация тиешле дәрәҗәдә булмау, җәмгыятьтә һәм эш бирүчеләр арасында өлкән яшьтәге кешеләр төркемнәренә карата стереотиплар.

Шул ук вакытта иң еш очракта кешене дәгъва итүченең квалификациясе җитәрлек булмау аркасында эшкә алмыйлар. Хезмәткәр компетенцияләренең эш бирүче таләпләренә туры килмәү проблемасы – яшь белән бәйле проблема, шуңа күрә өзлексез белем алу теләсә нинди яшьтәге кешеләр өчен хезмәт базарының реаль таләбе, зарурлык булып тора.

Ел саен эш эзләү максаты белән халыкны эш белән тәэмин үзәкләренә мөрәҗәгать итүчеләр арасында якынча 3 проценты пенсия алды яшендәге гражданнар тәшкил итә, аларның якынча 30 проценты эшкә урнаша.

Гражданнарның бер өлеше укырга һәм алынган һөнәре буенча хезмәт эшчәнлеген яңадан башлап җибәрергә әзер. Татарстан Республикасында һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем алуга җибәрелгән пенсия алды яшендәге затларның өлеше арту күзәтелә: әгәр 2017 елда аларның өлеше 3,1 процент тәшкил итсә, 2020 елда – 5,1 процент, 2021 елның беренче ярты еллыгында 7,9 процент тәшкил итте.

Хәзерге вакытта өлкән яшьтәге гражданнарны укыту чаралары тормышка ашырыла. Пенсия алды яшендәге гражданнарга һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру эше түбәндәге һөнәрләр буенча алып барыла: электр җиһазын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер, кондитер, каравылчы, пешекче, электрон хисаплау һәм хисаплау машиналары операторы.

Хезмәт базарында пенсия алды яшендәге эшсез гражданнарның конкурентлыкка сәләтен арттыру, алга таба аларны эшкә урнаштыру, бу максатчан категориянең үзмәшгульлеген яки эшмәкәрлеген оештыру максатларында һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү оештырыла, ә пенсия алды яшендәге хезмәткәрләрнең эш белән тәэмин ителешен яки башка эш урынына яки башка оешмага эшкә урнаштыруны саклап калу өчен халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан алга китеп һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү оештырылды.

Демографик вәзгыятьне һәм хезмәт базарындагы вәзгыятьне исәпкә алып, пенсия алды яшендәге гражданнарның белеменә һәм тәҗрибәсенә ихтыяҗ зур.

Моннан тыш, махсус тәҗрибәне һәм озак укуны таләп итми торган берничә һөнәргә даими тотрыклы ихтыяҗ күзәтелә.

Пенсия алды яшендәге гражданнар еш кына санитар, вахтер, каравылчы, бухгалтер, чишенү бүлмәсендә эшләүче, үлчәп төрүче, сатучы вакансияләренә урнаштырыла.

Татарстан Республикасында пенсия алды яшендәге гражданнарның эш белән тәэмин ителешен саклауны һәм үстерүне тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр карала:

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү, шул исәптән даими һәм вакытлы эш урыннарына эшкә урнашуда булышлык күрсәтү;

эшкә урнашу мәсьәләләре буенча «кайнар линия» оештыру;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә әлеге категория гражданнары белән эшләү буенча җаваплы хезмәткәрне беркетү;

пенсия алды яшендәге (хатын-кызлар өчен 50 яшь һәм өлкәнрәк, ир-атлар өчен 55 яшь һәм өлкәнрәк) хезмәткәрләрнең санын (штатын) кыскарту чараларын гамәлгә

ашыра торган эш бирүчеләр турында Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә (территориаль бүлекчәләргә) мәгълүмат тапшыру (әлеге хезмәткәрләрне эштән азат итүне планлаштыру турында мәгълүмат булуга);

халыкны эш белән тәэмин итү буенча актив сәясәт чараларын тормышка ашыру (һөнәри укытуны, вакансияләр ярминкәләрен, психологик һәм социаль адаптацияләүне кертеп), шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлегенә (үзмәшгульлеген кертеп) булышлык күрсәтү;

беренче тапкыр хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрүче яшьләр өчен әлеге категориядәге гражданнар тәҗрибәсен остазлар сыйфатында файдалану;

эшкә урнашуда булышлык күрсәткәндә информацион система – «Работа в России» порталыннан һәм эшлекле бәйләнешләр өчен социаль челтәрдән (SkilsNet) файдалану.

Хезмәткәрләрнең квалификациясе дәрәҗәсенә карата югары таләпләр куелган эш урыннары саны арту, һөнәри бурычларны хәл итүнең яңа ысулларын үзләштерү шартларында пенсия алды яшендәге гражданнарның заманча югары технологияле эшчәнлек өлкәләрендә тормышка ашырыла торган белемнәрен һәм күнекмәләрен яңарту зарурлыгы килеп туа.

Әлеге максатларга ирешү өчен пенсия алды яшендәге затларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча түбәндәге бурычлар хәл ителәчәк:

пенсия алды яшендәге гражданнарның һөнәри укытуга ихтыяҗын (шул исәптән социологик сораштыру үткәрү юлы белән) билгеләү;

пенсия алды яшендәге гражданнарны укыту өчен хезмәт базарында иң кирәкле һөнәрләр (күнекмәләр, компетенцияләр) исемлеген булдыру;

пенсия алды яшендәге гражданнарны укыту өчен белем бирү программалары банкын формалаштыру;

пенсия алды яшендәге хезмәткәрләрне укытуны һәм эшкә урнаштыруны оештыруга карата халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын яхшырту буенча системалы чараларны тормышка ашыру.

Пенсия алды яшендәге затларга эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чаралары планы Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының 3 нче кушымтасында китерелде.

Пенсия алды яшендәге затларны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү чараларының төп максатлары – пенсия алды яшендәге затларны эш белән тәэмин итүне саклап калу һәм киңәйтү, шулай ук аларның хезмәт потенциалыннан максималь файдалану.»;

«Демография» илкүләм проектының «Хатын-кызларның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын тудыру» төбәк проектын тормышка ашыру кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүче хатын-кызларның эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру» бүлекчәсе үз көчен югалткан дип танырга;

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекләре, аның максатлары, бурычлары һәм тормышка ашыру сроклары

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге б-1662 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак вакытлы социаль-икътисадый үсеше концепциясе нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп өстенлекләре:

алга таба даими эш урынына эш урнашу максаты белән оешмаларда яшь белгечләрнең стажировкалар үтү тәҗрибәсен арттыру;

балигъ булмаган балалары һәм инвалид балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итүне стимуллау;

физик мөмкинлекләре чикләнгән затларны хезмәт эшчәнлегенә интеграцияләү өчен, аерым алганда, инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыру, инвалидларны эш белән тәэмин итүгә даими булышлык күрсәтеп торуны оештыру юлы белән шартлар тудыру;

халыкка һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән мәктәп укучыларына һөнәри юнәлеш бирү системасын үстерү, хезмәт базарында иң кирәкле һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча хезмәт эшчәнлегенә карата аларның мотивациясен арттыру;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә яңа мәгълүмат бирү мөмкинлекләреннән файдалану һәм һәркем өчен мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү;

эчке хезмәт миграциясенә ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.

Әлеге дәүләт сәясәте өстенлекләреннән чыгып, Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы формалаштырылды, аның максатлары – халыкның эш белән тәэмин ителешен, шул исәптән хезмәт эшчәнлегенә инвалидларны җәлеп итү юлы белән булдыру һәм Татарстан Республикасы икътисады өчен кадрлар потенциалын үстерү.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык итү өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын яхшырту һәм алардан һәркем файдалану мөмкинлеген арттыру;

эш эзләүче гражданнарны эшкә урнаштыруга ярдәм күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыру;

гамәлдәге эш урыннарын саклап калуга һәм яңа эш урыннарын булдыруга булышлык күрсәтү;

эш бирүчеләрнең кадрларны комплектацияләүгә булган ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү;

эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру;

инвалидларны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү, инвалидларны эш белән тәэмин итүдә даими булышлык күрсәтеп торуны оештыру.

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар каралды:

хезмәт базарындагы хәлләр турында, шул исәптән социаль һәм хезмәт мөнәсәбәтләрен норматив-хокукый җайга салу, һөнәр-квалификация яктылыгында эш көченә сорау һәм тәкъдим, һөнәри квалификация, әзерлек, яңадан әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә ихтыяҗ булу турында мәгълүмат бирү; массакүләм мәгълүмат чаралары («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, радио һәм телевидение тапшыруын, вакытлы матбугатларны кертеп) аша халыкны халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнары һәм учреждениеләре тарафыннан тормышка ашыра торган чараларны яктыртып тору;

халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәт мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча мәгълүмат-белешмә материалларын әзерләү һәм бастырып чыгару (тиражлау);

предприятие (оешма) хезмәткәрләренең санын яки штатын кыскарту йә предприятиене (оешманы) бетерү планлаштырыла торган предприятиеләрдә (оешмаларда) махсуслаштырылган консультация пунктларын оештыру;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең мобиль офисларын файдаланып, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының, хәрби хезмәт ветераннарының хәзерге шартларда социаль-икътисадый һәм хокукый хәлен, матди хәл дәрәҗәсен һәм хокукый яктан якланганлыгын тикшерүне оештыру;

республика хезмәт базары торышына перспективалы фараз бирү максаты белән республиканың хезмәт ресурслары базарын тикшерү һәм анализлау һ.б.;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнар, урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнар, гомуми белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларының чыгарылыш укучылары арасыннан эшсез гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне, аларны вакытлыча эшкә урнаштыруны, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны, матди ярдәм күрсәтеп, вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру;

эшсез инвалидларга эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрүдә булышлык күрсәтү (индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга, эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органары юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп);

эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эшсез гражданнарның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау һәм эш бирүчегә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнаштырылган затларның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау;

түбәндәгеләрне алга китеп һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шул исәптән:

инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктуризацияләүне һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләрен;

эшчеләр һөнәрләре буенча яшьләр һәм студентлар хезмәт отрядларында катнашучыларның һөнәри әзерлеге;

конкурентлык сәләтен арттыру, алга таба эшкә урнашу, үзмәшгульлек һәм эшмәкәрлек максатларында эшсез гражданнарны, шул исәптән пенсия алды яшендәге эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру, шулай ук яраклы эш эзләү максатларында теркәлгән гражданнарны, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән эшсез гражданнарны һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башлап җибәрергә омтылучы башка категорияләрдәге пенсионерларны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә белем бирү;

эш (һөнәр) өлкәсен сайлап алу, эшкә урнашу, һөнәри уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга, шул исәптән гомуми белем бирү оешмалары укучыларына һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль адаптацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү һәм аларга психологик ярдәм күрсәтү, эшкә урнашканда даими булышлык күрсәтеп тору һәм социаль адаптацияләү буенча комплекслы хезмәт күрсәтү;

эшсез гражданнарга эшсезлек буенча пособиеләрне үз вакытында түләү һәм матди ярдәм күрсәтү юлы белән социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә эшсез гражданнар арасындагы затларга алдан рәсмиләштерелгән пенсияләрне түләү чыгымнарын каплау;

эш бирүчеләрнең квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыруга махсус эш урыннары булдыру чыгымнарын каплау;

инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидияләр бирү;

эш белән тәэмин ителмәгән инвалидларны эшкә урнаштыруда, шул исәптән алар өчен җиһазландырылган (җиһазланган) эш урыннарына урнаштыруда булышлык күрсәтүне оештыру;

эшсез инвалидларга эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрүдә булышлык күрсәтү (индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, оештырыла торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга, эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп);

эшләмәгән инвалидларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне, һөнәри юнәлеш бирүне, аларны хезмәт базарында социаль адаптацияләүне һәм аларга психологик ярдәм күрсәтүне оештыру һ.б.;

эш эзләгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен, оешмаларның эштән азат ителү рискындагы хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда эш бирүченең хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул исәптән:

эш эзләгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда эш бирүчеләрнең хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул ук вакытта аларның эшсезлек буенча пособие алу хокукы саклана;

оешмаларның эштән азат ителү рискындагы (тулы булмаган эш вакыты режимын кертү, эшләрне вакытлыча туктатып тору, эш хакы түләнми торган яллар бирү, хезмәткәрләрне эштән азат итү чараларын үткәрү) хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда эш бирүчеләрнең хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтләре нәтиҗәлелеген арттыру.

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасын тормышка ашыру йомгаклары буенча 2025 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсен 0,6 проценттан югарырак булдырмау;

халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен кимендә 61,5 процент тәэмин итү;

2025 ел ахырына эшсезлекнең уртача дәвамлылыгын 4,5 айга кадәр киметү;

теркәлгән эшсез гражданнар санының кимендә 12 процентының һөнәр дәрәҗәсен арттыруны тәэмин итү;

эш эзләү максаты белән халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән гражданнар санының кимендә 60 процентына һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

теркәлгән эшсез гражданнарның уртача еллык санының кимендә 70 процентын җәмәгать һәм вакытлы эшләрдә эш белән тәэмин итүне булдыру;

республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар саныннан әлеге яшьтәге гражданнарның укудан буш вакытта эш белән тәэмин ителешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы гамәлдә булган чорда эшләмәгән инвалидлар, күпбалалы ата-аналар һәм инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен 1,2 мең махсуслаштырылган эш урыны булдыру;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен эшсез гражданнарга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җиргә күчеп урнашуда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән гражданнарга әлеге дәүләт хезмәте 100 процент күрсәтелү;

кече эшмәкәрлек өлкәсенә кимендә 5 мең эшсез гражданны җәлеп итү;

Татарстан Республикасының икътисадый актив халкы саныннан кимендә 90 процентына хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү;

730 меңнән артык гражданны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

югары белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 55 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 65 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты һәм аннан күбрәк ай үткәннән соң эш тапкан, эшләгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алты һәм аннан күбрәк ай үткәннән соң эш тапкан, эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан чыгарылыш укучылар өлешен кимендә 0,5 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алга таба белем алуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан чыгарылыш укучылар өлешен кимендә 12 процент тәэмин итү;

эш эзләү максаты белән мөрәҗәгать иткән пенсия алды яшендәге затлар арасында эшкә урнашу өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү.

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары: 2014 – 2025 еллар.

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы бер этапта гамәлгә ашырылачак, бу каралган чараларның өзлексезлеген һәм дәвамчанлыгын тәэмин итәчәк.

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы максатлары, бурычлары һәм чаралары яктылыгында фаразлана торган индикаторлар күрсәткечләренең җентекле тасвирламасы 2 нче кушымтада китерелде.»;

Программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «27 618 284,78» саннарын «26 003 313,68» саннарына алмаштырырга;

икенче абзацта «18 786 536,50» саннарын «17 119 908,6» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «8 831 748,28» саннарын «8 883 405,08» саннарына алмаштырырга;

V бүлекнең бишенче абзацында «һәм үзмәшгульлегенә ярдәм күрсәтүне» сүзләрен «һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга ярдәм күрсәтүне» сүзләренә алмаштырырга;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасына 1 нче кушымтаның 21 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары» таблицасында Эшкә урнашканда яшь инвалидларга булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, аның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

1.4 пунктның 7 графасында «450» саннарын «400» саннарына алмаштырырга;

1.9 пунктның 15 графасында «437 677,8» саннарын «496 622,0» саннарына алмаштырырга;

2.2 пунктның 3 графасында «2019 – 2025 еллар» сүзләрен «2019 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның 15 – 19 графаларында «51 335,3» саннарын «0» санына алмаштырырга;

2.2.1 пунктның 7 – 11 графаларында «кимендә 70» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

2.2.2 пунктның 7 – 11 графаларында «кимендә 100» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

2.2.4 пунктның 7 – 11 графаларында «кимендә 15» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.4. Эшэзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнар, урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнар, гомуми белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларының чыгарылыш укучылары арасыннан эшсез | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИДУ | 2021 – 2025 еллар | | | | | | | | | ТР бюджеты | | | 51 335,3 | 51 335,3 | 51 335,3 | 51 335,3 | 51 335,3 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне, аларны вакытлыча эшкә урнаштыруны, матди ярдәм күрсәтеп, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.4.1. Эшсез гражданнар, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнар өчен түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне оештыру | | | теркәлгән эшсез гражданнарның уртача еллык санынnан эшсез гражданнарның җәмәгать эшләрендә һәм вакытлы эшләрдә эш белән тәэмин ителешен тәэмин итү, процент | | | кимендә 70 | кимендә 70 | кимендә 70 | кимендә 70 | кимендә 70 | | | | | | | | |
| 2.4.2. Эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез | | | дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап мөрәҗәгать | | | кимендә 100 | кимендә 100 | кимендә 100 | кимендә 100 | кимендә 100 | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гражданнарны, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | | | итүчеләр саныннан вакытлыча эшләргә урнаштырылган пенсия алды яшендәге гражданнар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| 2.4.3. Урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | | | дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр саныннан урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнар өлеше, процент | | | не менее 55 | не менее 55 | не менее 55 | не менее 55 | не менее 55 | | | | | | | | |
| 2.4.4. Матди ярдәм күрсәтеп, 14 яшьтән 18 яшькә | | | республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге | | | кимендә 10 | кимендә 10 | кимендә 10 | кимендә 10 | не менее 10»; | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | | | балигъ булмаган гражданнар арасыннан укудан буш вакытта әлеге яшьтәге гражданнарны вакытлыча эш урыннарына эшкә урнаштыру белән тәэмин ителеш, эшкә урнаштырылганнар проценты | | | | | | | | | | | | | | | |

3.1 пунктта:

3 графада «2019 – 2025 еллар» сүзләрен «2019 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

7 – 11 графаларда «кимендә 0,6», «кимендә 50» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

15 – 17 графаларда «63 645,0» саннарын «0» санына алмаштырырга;

18 – 19 графаларда «66 504,90» саннарын «0» санына алмаштырырга;

3.1.1 пунктта:

15 – 17 графаларда «1 252,0» саннарын «0» санына алмаштырырга;

18 – 19 графаларда «1 372,4» саннарын «0» санына алмаштырырга;

3.1.2 пунктта:

15 – 17 графаларда «62 393,0» саннарын «0» санына алмаштырырга;

18 – 19 графаларда «65 132,5» саннарын «0» санына алмаштырырга;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3.5. Эшсез гражданнарның, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнарның | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИ ДУ | 2021 – 2025 еллар | хисап чорында теркәлгән эшсез гражданнарның гомуми | | | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | кимендә 0,6 | ТР бюджеты | | | 63 645,0 | 63 645,0 | 63 645,0 | 66 504,9 | 66 504,9 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү (шул исәптән оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне кертеп), индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, төзелә торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда граждан-нарга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс | | | санында үз эшен ачып җибәргәннәр өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүчеләр санынннан дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдаланган пенсия алды яшендәге эшсез гражданнар өлеше, процент | | | кимендә 50 | кимендә 50 | кимендә 50 | кимендә 50 | кимендә 50 | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ярдәме күрсәтү, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 3.5.1. Гражданнарга оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтү һәм тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | 1 252,0 | 1 252,0 | 1 252,0 | 1 372,4 | 1 372,4 |
| 3.5.2. Эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда гражданнарга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | 62 393,0 | 62 393,0 | 62 393,0 | 65 132,5 | 65 132,5»; |

4.1 пунктның 15 графасында «117 644,6» саннарын «110 357,2» саннарына алмаштырырга;

5.1 пунктның 15 графасында «3 251 673,6» саннарын «1 626 253,2» саннарына алмаштырырга;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.2. Стипендия түләү өлешендә эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга түләүләрне башкару | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИДУ | 2019 – 2021 еллар | белем алучы гражданнарның гомуми санында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары | 100 | 100 | 100 | | | | | ТР бюджеты | 40 569,4 | 36 449,5 | 18 792,5»; | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | юлламасы буенча һөнәри уку чорында стипендия алучы гражданнар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.3. Эшсез гражданнар арасыннан вакытыннан алда рәсмиләштерелгән пенсияләрне түләү буенча Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә чыгымнарны каплау | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИДУ | 2019 – 2020 еллар | квота кысаларында булдырылган эш урыннарына эшкә урнаштырылган эшсез инвалидлар өлеше, процент | кимендә 100 | кимендә 100 | | | | | | ТР бюджеты | 60 000,0 | 41 800,0 | 56 000,0 | 67 000,0 | 67 000,0 | 57 014,0 | 57 014,0»; |
| | | 2021 – 2025 еллар | эшсез гражданнарның уртача еллык санына карата үз вакытыннан алда пенсия алучы эшсез гражданнар өлеше | | | 1,7 | 1,7 | 1,7 | 1,7 | 1,7 | | | | | | | | |

6.4 пунктта:

3 графада «2019 – 2025 еллар» сүзләрен «2019 – 2020 еллар» сүзләренә алмаштырырга;

7 – 11 графаларда «кимендә 1» сүзләрен «0» санына алмаштырырга;

15 – 17 графаларда «1 480,0» саннарын «0» санына алмаштырырга;

18 – 19 графаларда «1 202,0» саннарын «0» санына алмаштырырга;

3 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.5. Эшсез инвалидларның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү (шул исәптән оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне кертеп), индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алганда, төзелә торган юридик затны дәүләт теркәвенә алганда, крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алганда, физик затны һөнәри керемгә салым түләүче буларак исәпкә куйганда инвалидларга бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү, | ТР Хезмәт министрлыгы, ХЭТИ ДУ | 2021 – 2025 еллар | дәүләт хезмәте күрсәтелгән эшсез гражданнарның гомуми саныннан дәүләт хезмәте күрсәтелгән эшсез инвалидлар өлеше, процент | | | кимендә 1 | кимендә 1 | кимендә 1 | кимендә 1 | кимендә 1 | ТР бюджеты | | | 1 480,0 | 1 480,0 | 1 480,0 | 1 202,0 | 1 202,0 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен доку-ментлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган фи-нанс ярдәме күрсәтү, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 6.6.1. Ин-валид-лар-га оешты-ру-кон-сультация хезмәтлә-ре күрсәтү һәм тиеш-ле дәүләт теркәвенә алу өчен документ-лар әзер-ләүгә бер тапкыр бирелә торган фи-нанс ярдә-ме күр-сәтү | | | | | | | | | | | | | | 29,0 | 29,0 | 29,0 | 26,0 | 26,0 |
| 6.6.2. Эш-мәкәрлек эшчәнле-ген дәүләт теркәвенә алганда инва-лидларга бер тапкыр бирелә торган фи-нанс ярдәме күрсәтү | | | | | | | | | | | | | | 1 451,0 | 1 451,0 | 1 451,0 | 1 176,0 | 1 176,0»; |

«Ярдәмче программа буенча барлыгы» юлының 15 графасында «4 150 197,4» саннарын «2 535 226,3» саннарына алмаштырырга;

«җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы» юлының 15 графасында «3 369 261,2» саннарын «1 702 633,3» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты акчасы» юлының 15 графасында «780 936,2» саннарын «832 593,0» саннарына алмаштырырга;

3 нче кушымтаның 6 пунктындагы 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Эшсез гражданнарның, шул исәптән пенсия алды яшендәге гражданнарның эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауга булышлык күрсәтү (оештыру-кон-сультация бирү хезмәтләре күрсәтүне кертеп), гражданнарга эшмәкәрлек эшчәнлеген

дәүләт теркәвенә алганда бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтү»;

«Татарстан Республикасында эшчеләр һәм инженерлар һөнәрләрен популярлаштыру» ярдәмче программасында:

ярдәмче программаның V бүлегендәге унынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

ярдәмче программа кушымтасындагы «Татарстан Республикасында эшчеләр һәм инженерлар һөнәрләрен популярлаштыру» ярдәмче программасы максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасының 1.1.1 пунктындагы 7 графасында «1» санын «0» санына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 ноябрь, 1055 нче карары редакциясендә)

## «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

| Ярдәмче программаның исеме | Финанслау чыганаклары | Еллар буенча финанслау күләме, мең сум | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп | барысы | 1 611 314,39 | 1 388 721,01 | 1 410 779,48 | 1 315 776,8 | 1 315 863,1 | 1 876 479,8 | 5 356 930,6 | 2 535 226,3 | 2 950 104,4 | 2 977 138,0 | 1 632 489,9* | 1 632 489,9* |
| | Татарстан Республикасы бюджеты | 654 277,79 | 617 082,01 | 668 736,98 | 705 897,7 | 740 695,0 | 752 250,2 | 769 783,2 | 832 593,0 | 777 557,2 | 778 236,8 | 793 147,6* | 793 147,6* |
| | федераль бюджет (җәлеп итәргә планлаштырыла торган чаралар) | 957 036,6 | 771 639,0 | 742 042,5 | 609 879,1 | 575 168,1 | 1 124 229,6 | 4 587 147,4 | 1 702 633,3 | 2 172 547,2 | 2 198 901,2 | 839 342,3* | 839 342,3* |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тору | | | | | | | | | | | | | |
| Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту | Татарстан Республикасы бюджеты | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0 | 4 630,0* | 4 630,0* |
| Татарстан Республикасында эшчеләр һәм инженерлар һөнәрләрен популярлаштыру | Татарстан Республикасы бюджеты | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 735,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | 0,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 000,0 | 10 000,0* | 10 000,0* |
| Программа буенча барлыгы, шул исәптән: | | 1 625 944,39 | 1 403 351,01 | 1 425 409,48 | 1 331 141,8 | 1 330 493,1 | 1 891 109,8 | 5 361 560,6 | 2 549 856,3 | 2 964 734,4 | 2 991 768,0 | 1 647 119,9* | 1 647 119,9* |
| Татарстан Республикасы бюджеты | | 668 907,79 | 631 712,01 | 683 366,98 | 721 262,7 | 755 325,0 | 766 880,2 | 774 413,2 | 847 223,0 | 792 187,2 | 792 866,8 | 807 777,6* | 807 777,6* |
| федераль бюджет (җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча) | | 957 036,6 | 771 639,0 | 742 042,5 | 609 879,1 | 575 168,1 | 1 124 229,6 | 4 587 147,4 | 1 702 633,3 | 2 172 547,2 | 2 198 901,2 | 839 342,3* | 839 342,3* |

*2024 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.